КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1502

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2023 ел, 2 ноябрь, 1409 нчы карары белән расланган Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2023 ел, 02 ноябрь, 1409 нчы карары белән расланган Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

«мобилизация буенча чакырылган» сүзләрен «өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган» сүзләренә алмаштырырга;

«Россия Федерациясе Оборона министрлыгы» сүзләреннән соң «яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта исемендә «мобилизация буенча чакырылган» сүзләрен «өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта исемендә «Россия Федерациясе Оборона министрлыгы» сүзләреннән соң «яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин